ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

17 ноябрь, 2020 ел №2/3

Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге 24/7 номерлы Карары белән расланган аерым муниципаль учреждениеләр җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 15 октябрендәге «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1097 номерлы карары белән расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләр иминлеген тәэмин итү өлкәсендәге Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 930 номерлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 16 октябрендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы Карары белән расланган Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләрне формалаштырганда исәпкә алына торган муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү методикасының 2 нче кушымтасына үзгәреш кертү хакында» 935 номерлы Карары нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2018 елның 27 апрелендәге 24/7 номерлы Карары белән расланган аерым муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре һәм хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәгә (Шәһәр Советының 2018 елның 10 августындагы 26/8, 2018 елның 8 ноябрендәге 27/10, 2019 елның 23 маендагы 31/6, 2020 елның 6 февралендәге 36/5, 2020 елның 23 сентябрендәге 1/13 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 13 пунктта:

- «7 499» саннарын «7 724» саннарына алыштырырга;
- «6 823» саннарын «7 028» саннарына алыштырырга;

2) 15.2 пунктта 1 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 таблица

Учреждениенең аерым категория хезмәткәрләрнең
вазыйфаи окладлары

| Вазыйфа исеме | Вазыйфаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Җитәкче | 18 248 |
| Баш хисапчы | 12 774 |
| Каравыл башлыгы | 13 117 |
| Янгын сүндерү бүлеге командиры | 12 200 |
| Янгын сүндерү машинасы йөртүчесе | 9 297». |

2.Әлеге Карар рәсми бастырылган көннән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән соң хасил булган хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тоту Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев